РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЯТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЯТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2021 № 2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Кыят авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе
турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 11 апрелендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә ( алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 4.2 пунктка түбәндәге редакциядә абзац өстәргә:

«Аукцион үткәрмичә урнаштыру өчен шартнамә төзү хокукы барлыкка килүнең мәҗбүри шарты-Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотам.

ТР Буа муниципаль районы
Кыят авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Е.С. Корунова